КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 октябрь г.Казань № 956

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле турында

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының максатларын һәм бурычларын формалаштырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законның 6, 13 статьялары, «Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль законның 5, 24 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешенә иҗтимагый контроль алып бару тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – вәкаләтле органнар) ел саен 31 декабрьгә кадәр, чираттагы елга үз максатларын һәм бурычларын гавами формалаштыруны Тәртип нигезендә тәэмин итәргә.

3. «Татарстан Республикасының Мәгълүмати технологияләр үзәге» Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиесен вәкаләтле органнар максатларын һәм бурычларын гавами формалаштыру буенча техник оператор итеп билгеләргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына вәкаләтле органнар белән берлектә, вәкаләтле органнарның максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыру һәм аларның үтәлешен массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртуны тәэмин итәргә кирәк.

5. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына ел саен, 30 сентябрьгә кадәр, вәкаләтле органнарның максатларын һәм бурычларын ачык формалаштыруда катнашу һәм аларның үтәлешенә җәмәгать контроле өчен экспертларны сайлап алу тәртибен һәм критерийларын расларга, шулай ук һәр вәкаләтле орган өчен экспертлар төркеме составын формалаштырырга тәкъдим итәргә.

6. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карар 2020 елга һәм аннан соңгы елларга вәкаләтле органнарның максатларын һәм бурычларын ачык формалаштырганда барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә һәм аларның үтәлешен җәмәгать контроленә карата кулланыла;

әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 20 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары максатларын һәм бурычларын гавами Формалаштыру һәм аларның үтәлешенә иҗтимагый контроль буенча сынау проектын гамәлгә ашыру турында» 2018 ел, 24 август, 709 нчы карары 2020 елның 1 мартыннан үз көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында социаль активлыкның һәм интерактив сервисларның интеграцияләнгән платформасын үстерү буенча ведомствоара проект төркеме турында» 2017 елның 4 мартындагы 160 номерлы боерыгы белән төзелгән Татарстан Республикасында социаль активлыкның һәм интерактив сервисларның интеграцияләнгән платформасын үстерү буенча ведомствоара проект төркеменә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин